**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 11 июнь № 431

г. Казань

Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүнең сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен түләү зурлыгын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 216.1 статьясы, «Хезмәт шартларын махсус бәяләү турында» 2013 ел, 28 декабрь, 426-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 12 август, 549н номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлә торган Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүнең сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен түләү зурлыгын билгеләү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\431.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 11 июнь, 431 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүнең сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен түләү зурлыгын билгеләү
тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип «Хезмәт шартларын махсус бәяләү турында» 2013 ел, 28 декабрь, 426-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 2 пунктның 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүнең сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен түләү зурлыгын билгеләүне (алга таба – экспертиза) үткәрү вәкаләтләре бирелгән Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы) турыдан-туры тапшырылган хезмәткәрләр, һөнәри берләшмәләр, аларның берлекләре, хезмәткәрләр тарафыннан вәкаләтләр бирелгән бүтән вәкиллекле органнар, шулай ук эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре, иминиятләүчеләр гаризасы буенча (алга таба – гариза) экспертиза билгеләү максатларында эшләнде.

2. Экспертиза үткәргән өчен түләү зурлыгын билгеләү экспертиза үткәрүгә норматив чыгымнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

## II. Экспертиза үткәрүгә норматив чыгымнарны билгеләү

3. ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына турыдан-туры кергән гариза экспертиза үткәргәнгә түләү алу өчен нигез булып тора.

4. Экспертиза үткәрүгә түләү зурлыгы түбәндәге формула белән билгеләнүче, экспертизаның [1] бер объектына мөнәсәбәттә экспертиза үткәрүгә норматив чыгымнар нигезендә билгеләнә:

$$N_3 = N_{от} * (1 + К_{кр}) + N_{кр},$$

монда:

$N_3$ – экспертизаның бер объектына мөнәсәбәттә экспертиза үткәрүгә норматив чыгымнар;

[1] Экспертиза объекты дигәндә хезмәт шартларына мөнәсәбәттә хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрелгән эш урыны аңлашыла

$N_{от}$ – экспертиза үткәрүче ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре хезмәтенә түләүгә һәм хезмәткә түләүгә өстәмә исәпләүләргә еллык чыгымнар нормативы;

$К_{кр}$ – экспертиза үткәрүче ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре хезмәтенә түләүгә, хезмәткә түләүгә өстәмә исәпләүләрне исәпкә алып, еллык чыгымнар нормативына карата элемтә хезмәтен күрсәтүгә, канцелярия кирәк-яраклары, чыгым материаллары һәм хуҗалык инвентаре сатып алуга түләүнең еллык чыгымнар нормативы мөнәсәбәте булып исәпләнә торган турыдан-туры булмаган чыгымнар коэффициенты;

$N_{кр}$ – экспертиза үткәрүче ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең командировкаларына тотылган акчага норматив чыгымнар.

турыдан-туры булмаган чыгымнар коэффициенты ($К_{кр}$) тиешле чыгымнарны исәпләү нигезендә билгеләнә, бу чакта аның мәгънәсе экспертиза үткәрүче ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре хезмәтенә түләүнең һәм хезмәткә түләүнең еллык фондының 35 процентыннан артып китә алмый.

5. Экспертиза үткәрүче ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре хезмәтенә түләүгә һәм хезмәткә түләүгә өстәмә исәпләүләргә чыгымнар нормативы ($N_{от}$) Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында» 2006 ел, 5 апрель, ПУ-133 номерлы Указы нигезендә исәпләнгән хезмәт хакы зурлыклары нигезендә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$N_{от} = \sum З_{фот} * Т / \sum Ф_{р.вр.},$$

монда:

$\sum З_{фот}$ – Экспертиза үткәрүче ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре хезмәт хакларын түләүнең еллык фонды;

$\sum Ф_{р.вр.}$ – җитештерү календаре буенча бер елга (көннәргә) Экспертиза үткәрүче ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш вакыты фонды;

Т – экспертизаның бер объектына мөнәсәбәттә экспертиза үткәрүгә куелган көч (кеше-көн).

## III. Экспертиза үткәрүгә куелган көчне билгеләнү

6. Экспертизаның бер объектына мөнәсәбәттә экспертиза үткәрүгә куелган көч түбәндәге формула буенча кеше-көннәрдә исәпләнелә:

$$Т = Т_{эксп} + Т_{изм},$$

монда:

$Т_{эксп}$ – тикшеренүләр (сынаулар) һәм җитештерүнең зарарлы һәм (яки) куркыныч факторларын үлчәүләр үткәрмичә экспертиза үткәрүгә куелган көч;

$Т_{изм}$ – тикшеренүләр (сынаулар) һәм җитештерүнең зарарлы һәм (яки) куркыныч факторларын үлчәүләр үткәрүгә куелган көч.

Экспертиза үткәрүгә куелган көч әлеге Тәртипкә кушымтада каралган эшләр составы һәм максималь куелган көч нигезендә билгеләнә:

$$Т_{эксп} = (Т_{эксп1} + Т_{эксп2} + Т_{эксп3}) * К,$$
$$Т_{изм} = Т_{изм1} * К$$

монда:

$Т_{эксп1}$, $Т_{эксп2}$, $Т_{эксп3}$, $Т_{изм1}$ – экспертизаның бер объектына карата экспертиза үткәрү буенча эшләрнең аерым төрләрен башкаруга куелган көч;

К – төзәтмәләр кертүче коэффициент.

Экспертиза объектлары саны 5 тән ким булганда 1 гә тигез, гаризада күрсәтелгән экспертиза объектлары саны 5 тән 50 гә кадәр булганда 1,5 кә, экспертиза объектлары саны 50 дән артык булганда 2 гә тигез төзәтүләр кертүче коэффициент билгеләнә.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

7. Хезмәт шартларын махсус бәяләүнең сыйфатына экспертиза үткәргән өчен түләү зурлыгы әлеге Тәртиптә каралган һәр гариза бирүчегә аерым чыгымнар исәбен төзү юлы белән ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

7.1. Хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрүнең сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен алынган акча Татарстан Республикасы бюджетына керә.

Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүнең сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен түләү зурлыгын билгеләү тәртибенә кушымта

Хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүнең сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү буенча эшләрнең төре, составы һәм куелган көчләр

ИСЕМЛЕГЕ

| Т/с | Эш төрләре | Эшләрнең составы | Эш төрләренә максималь куелган көч (кеше-көн) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Экспертиза объектлары турында мәгълүматларны һәм аны үткәрү өчен аларның җитәрлек булуын билгеләү максатларында экспертиза үткәрү өчен нигезләрне теркәү һәм карап тикшерү ($Т_{эксп1}$) | Гаризаны теркәү.<br>Экспертиза үткәрү өчен ТР Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрен (алга таба – дәүләт эксперты) яки дәүләт экспертлары төркемнәрен (эксперт комиссиясен формалаштыру) билгеләү.<br>Гаризадагы экспертиза объектлары турында мәгълүматларның тулылыгын, аны үткәрү өчен аларның җитәрлек булуын билгеләү.<br>Экспертиза үткәрү турында (яки үткәрүдән баш тарту турында) карар кабул итү.<br>Экспертиза үткәрү өчен документларны дәүләт экспертына/ эксперт комиссиясенә тапшыру яки экспертиза үткәрүдән дәлилләнгән баш тарту | 0,8 |
| 2. | Экспертиза үткәрү ($Т_{эксп2}$) | хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәргән оешма, аның сынау лабораториясе (үзәге) һәм үлчәү | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | чаралары, экспертлары һәм хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүдә катнашкан бүтән белгечләре турында белешмәләрне өйрәнү һәм бәяләү.<br>Зыянлы һәм (яки) куркыныч булуы ихтимал җитештерү факторларын тәңгәлләштерү материалларын өйрәнү һәм бәяләү.<br>Зыянлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторларын тикшерү (сынау) һәм үлчәү материалларын өйрәнү һәм бәяләү.<br>Эш урынындагы хезмәт шартларын хезмәт шартларының классына (ярдәмче классына) кертеп карау материалларын өйрәнү һәм бәяләү.<br>хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү турында хисаптагы бүтән мәгълүматларны һәм белешмәләрне өйрәнү һәм бәяләү. | |
| 3. | Билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән сынау лабораторияләрен (үзәкләрен) җәлеп итеп, эш урынын тикшерү һәм җитештерү факторларын тикшерүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү (кирәк булганда).<br>( $T_{изм1}$ ) | Хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрелгән эш урыны һәм тиешле технологик процесслар белән танышу.<br>Эш урынын, технологик процессларны, кулланыла торган машиналарны, җиһазларны һәм коралларны, шулай ук чимал һәм материалларны сыйфатлаучы документлар белән танышу.<br>Эш урынында мәшгуль хезмәткәрдән (хезмәткәрләрдән), хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү комиссиясе әгъзаларыннан сораштыру.<br>Гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән сынау лабораторияләрен (үзәкләрен) җәлеп итеп, эш урынында җитештерү факторларын тикшерүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү | 2 |
| 4. | Экспертиза нәтиҗәләрен рәсми- | Экспертиза бәяләмәсе проектын әзерләү. | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ләштерү ( $Т_{эксп3}$ ) | Экспертиза бәяләмәсе килештерү, раслау һәм гариза бирүчегә юллау. | |